**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1034

г. Казань

Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 6 нчы пункт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы вәкаләтле орган булып тора дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның (алга таба – объект), масштаблы инвестицион проектның (алга таба – проект) Татарстан Республикасы Җир кодексында һәм Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү рөхсәт ителә торган масштаблы инвестицион проектлар туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 ел, 7 декабрь, ПУ-1170 нче Указында (алга таба – Татарстан Республикасы Президенты Указы) билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны кабул итү һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыручы;

объектны урнаштыру яки проектны гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү турындагы үтенечнамәләрне кабул итүне гамәлгә ашыручы;

объектны урнаштыру яки проектны гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү турындагы үтенечнамәне үз эченә алган юридик затлар мөрәҗәгатьләренең җыелма реестрын алып бару буенча;

объектның, проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында һәм Татарстан Республикасы Президенты Указында билгеләнгән критерийларга туры килүе турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын әзерләү буенча.

3. Объектның, проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында һәм Татарстан Республикасы Президенты Указында билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы документларны карап тикшерү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бәяләмәләр проектларын килештерү буенча вәкаләтле органнар итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын мәдәният, сәнгать, кинематография объектларын урнаштырганда һәм министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын спорт объектларын урнаштырганда һәм министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын сәламәтлек саклау объектларын урнаштырганда һәм министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын мәгариф һәм тәрбия эшләре объектларын урнаштырганда һәм министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү объектларын урнаштырганда һәм министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектларын урнаштырганда һәм министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын коммуналь хуҗалык, төзекләндерү объектларын, гидротехника корылмаларын, күпкатлы һәм (яки) җир асты транспорт туктап тору урыннарын (транспорт кую урыннарын), күпкатлы гаражлар урнаштырганда, намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән гражданнарның – күпфатирлы йортларның өлешле төзелешендә катнашучыларның хокукларын яклау буенча чаралар күрү өчен шәхси торак йортлар һәм (яки) күпфатирлы йортлар төзегәндә, министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган

проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын дәүләт (муниципаль) һәм шәхси индустриаль паркларны (сәнәгать паркларын), муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданнарын, төбәк инжиниринг үзәкләрен һәм прототиплаштыру үзәкләрен төзү һәм үстерү проектларны тормышка ашырганда.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясы нигезендә җир кишерлекләрен сатулар үткәрмичә бирү турында Татарстан Республикасы Президенты боерыклары проектларын әзерләү буенча вәкаләтле орган дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына объектның, проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы бәяләмә формасын эшләргә.

6. Министрлыкларга һәм ведомстволарга:

үзләренең ведомство норматив актларын әлеге карарга туры китерергә;

әлеге карарны кабул иткән көннән бер ай эчендә министрлыклар һәм ведомстволар турындагы нигезләмәләргә бу карарны тормышка ашыру өлешендә тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков